**СОВЕТ**
**Салаушского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Салагыш авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.02.2020 Салагыш авылы № 58-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 гыйнварындагы 49-1 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Салагыш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау турында карарга» Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасының 20.01.2020 № 02-08-01/19 протестын үтәү йөзеннән, «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, ««Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 436-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Советы **к а р а р и т т е:**

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 гыйнварындагы 49-1 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 12нче өлешнең 12.1. пунктындагы 2нче пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел

профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) түләүсез катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән түләүсез идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашудан тыш), Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиле рөхсәте белән катнашу,

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән, муниципаль хокукый актлар яки муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибе нигезендә муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (акционер, анда катнашучы), оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче булган идарә органнарында һәм оешманың ревизия комиссиясендә, муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен яклау

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;».

1.2. 12нче өлешнең 12.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле 12нче пунктча белән тулыландырырга:

«2.1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә.».

1.3. 16нчы өлешнең 16.3. пунктының 4нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;».

1.4. 16нчы өлешнең 16.3. пунктының 6нчы пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«6) шәхси (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, шул исәптән электрон документ формасында;».

1.5. 26нчы өлешнең 26.2 пунктчасындагы икенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм гамәлдән чыгару тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.».

1.6. 27нче өлешнең 27.9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«27.9. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 14.1, 15 һәм 27 статьяларында каралган түләтүләр, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсезлеге, ялында булу чорларын санамыйча, муниципаль хезмәткәр тарафыннан коррупциячел хокук бозу кылу турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча һәм коррупцион

хокук бозу кылган көннән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытка җинаять эше буенча производство вакыты кертелми.».

1.7. 29нчы өлешнең 29.6 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«29.6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы буенча тиешле елларны эшләгән өчен пенсиянең максималь күләмен исәпләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең тиешле вазыйфасы буенча (әгәр вазыйфаи оклад максималь һәм минималь әһәмияткә ия булса) вазыйфаи окладның максималь күләме кулланыла, ә класс чины өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын билгеләүче Норматив хокукый актында билгеләнгән мәгънәдә исәпкә алына.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе М.М.Мөхәмәдиев